ГЛАВА ЧУКМАРЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

**20 март 2024 ел**

**№1**

2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы авылы гражданнары халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында" мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге
Чукмарлы авылы гражданнарының халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. "2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы авылы гражданнарының халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында" мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы авылы гражданнары халык җыенын Чукмарлы авылы мәдәният йорты бинасында, Чукмарлы авылы Совет урамы 41 йорт адресы буенча, 2024 елның 30 мартына 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы авылы гражданнарының халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы

авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә Сез ризамы:

«1. Традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Чукмарлы торак пунктындагы зират территориясен киңәйтү, төзелеш материаллары сатып алу һәм койма урнаштыру буенча эш өчен түләү);

2. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Чукмарлы авылында лампаларны, энергияне сак тотучы тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру);

3. Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (Комсомол, Совет урамы су башняларын ремонтлау)

4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чукмарлы авылында Комсомол урамы, Совет урамы, Яшьләр урамнары буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материаллар сатып алу һәм транспортлау, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

5. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Чукмарлы авылында триммерлар һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу; МТЗ 82 тракторына ягулык-майлау материаллары сатып алу.

“ӘЙЕ” “ЮК”?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Чукмарлы авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Хадиуллин